РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов
урам, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

19.09.2020 — № 8

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 4 нче июлендәге 19 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 июлендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителүче муниципаль берәмлек яки аның елешендә яшәүче уналты яшькә җиткән гражданнар катнашырга хокуклы.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан

Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемә алам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев